## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ
## КАРАРЫ

**№ 2** **02 декабрь 2023 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
Районы Туйкә авыл җирлеге составына керүче
Туйкә авылында 2024 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Туйкә авылында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Туйкә авыл җирлеге Туйкә торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучы ирекле көчләргә, контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылучылар тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 (Дүрт йөз) сум күләмендә, 2 группа инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен 200 (Ике йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

- Түйкә авылын урам яктырту җайланмасы (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар, урам яктыртуны ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү буенча хезмәтләр сатып алу һәм алыштыру);
- Түйкә торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау, тоту(Түйкә авылына юлларны кардан чистарту, Киров урамында вак ташлар сатып алу, ташу, салу (килешү буенча эш өчен түләү, тракторчыга хезмәт хакы түләү));
- традицион Күмү урыннарын төзекләндерү (куакларны кисү, экскаватор белән төпләрне кысу, гербицид алу, тулаем гербицид белән химик эшкәртү, үләнне кисү, килешү буенча эш өчен түләү)
- Түйкә авылында халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгару (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм тоту, коеларны ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү, материаллар ,җиһазлар сатып алу, авария хәлләрен бетерү, торбаларны алмаштыру, килешү буенча эш өчен түләү) оештыру;
- халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү - «Сабантуй " майданы (сәхнә, беседка, гирлянд, капка сатып алу; баганалар сатып алу һәм урнаштыру,); балалар мәйданчыгы (тирбәлеш, тау, карусель,) һәм янәшәдәге халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерү (чүп үләннәрен чистарту һәм чүп үләннәрен кисү)

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы, Җәлил ур.,19 йорт;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы Гагарин ур., 4а йорт.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Туйкә авыл җирлеге Башлыгы Закирова Р.Р.